| | | |
|---|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 29 декабрь № 1002

г. Казань

Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләре санын азайту һәм алар сала торган зыяннар авырлыгын киметү буенча өстәмә чаралар турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 ел, 6 декабрь, ПУ-1115 нче Указын тормышка ашыру, юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләре санын азайту һәм алар сала торган зыяннар авырлыгын киметү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы министрлыкларына, дәүләт комитетларына, ведомстволарына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларына гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

әлеге карарда күздә тотылган чараларны тормышка ашыруны оештыруны;

квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 5 сенә кадәр, Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе секретариатына хисап кертүне.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Халык инспекторы» дәүләт мәгълүмат системасыннан иң актив файдаланган гражданнар өчен акчалата бүләкләү тәртибен эшләргә.

3. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына:

2016 елның 1 апреленә кадәр төбәк автомобиль юлларында автомобиль транспортының әйләнеп каплануыя яки кюветка төшеп китүенә китергән юл-транспорт һәлакәтләре тупланган урыннарда металл киртәләр урнаштыру һәм аларны алмаштыру планын эшләргә һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән килештерергә;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары белән берлектә, 2016 елның 1 августына кадәр мәктәп автобуслары маршрутлары үтә торган автомобиль юлларын норматив

куркынычсызлык таләпләренә туры китерү чараларын 2016 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы нигезендә төгәлләргә;

2016 ел эчендә түбәндәгеләрне дәвам итәргә:

Горький тимер юлы – «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы, Куйбышев тимер юлы – «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы белән килештереп, тимер юл аркылы чыгу урыннарын норматив хәлгә китерүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашыруны;

халыкка хезмәт күрсәтү оешмалары һәм белем бирү оешмалары янындагы икенче дәрәҗәдәге автомобиль юлларына тоташкан урыннарда, торак пунктлар урамнары кисешкән урыннарда хәрәкәт тизлеген мәҗбүри киметү чараларын (ясалма тигезсезлекләр) кую буенча чаралар комплексын тормышка ашыруны;

Юл хәрәкәте кагыйдәләрен саклауны тикшерүдә тоту җайланмаларын ялгау мөмкинлеген тәэмин итеп, төбәк әһәмиятендә булган гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының һәлакәтләр була торган участокларында ясалма яктырткычлар куюны;

илкүләм стандартлар таләпләре нигезендә, беренче чиратта, белем бирү оешмалары янында җәяүлеләр хәрәкәте өчен имин һәм уңайлы шартлар тудыру чараларын тормышка ашыруны.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

2016 елның 1 мартына кадәр:

медицина учреждениеләренең архив алкотестер күрсәткечләрен медицина таныклауларын теркәү журналындагы мәгълүматлар белән чагыштырып тикшерүне үткәрү тәртибен раслый торган күрсәтмәне эшләргә һәм ведомство буйсынуындагы оешмаларга җибәрергә;

зыян күрүчеләрне юл-транспорт һәлакәте урыннарыннан эвакуацияләү һәм медицина оешмаларына илтү өчен вертолет техникасыннан файдалану концепциясен эшләргә;

2016 ел дәвамында түбәндәгеләрне дәвам итәргә:

ашыгыч медицина ярдәме станцияләре (бүлекләре) фельдшерларын манекен-симуляторлар кулланып укытуны;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән берлектә, Татарстан Республикасының янгыннан коткару бүлекчәләре хезмәткәрләрен «Беренчел ярдәм күрсәтү» курсы буенча укытуны;

федераль махсуслаштырылган медицина үзәкләре белгечләрен җәлеп итеп, юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә видеоконференция элемтәсе режимында консультация ярдәме күрсәтү эшен.

5. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә, 2016 елның 1 июненә кадәр фотога төшерү һәм видеога язып алу системаларыннан файдаланып чыгарылган административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча карарлар күчермәләрен шәхси электрон почта ярдәмендә алу хезмәтен Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре порталы аша күрсәтү мәсьәләсен хәл итү.

6. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары белән берлектә, 2016 елның 1 августына кадәр Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Транспорт чараларына куела торган тахографларга таләпләрне, тахографлар белән җиһазландырыла торган транспорт чараларының категорияләрен һәм төрләрен, транспорт чараларына куелган тахографларны куллану, хезмәт күрсәтү һәм аларның эшләвен тикшерүдә тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2013 ел, 13 февраль, 36 нчы боерыгы таләпләре нигезендә мәктәп автобусларының тизлеге һәм хәрәкәт маршруты, йөртүченең эш һәм ял режимы хакындагы мәгълүматны өзлексез һәм төзәтмәләр кертмичә теркәүне тәэмин итүче техник тикшерүдә тоту чаралары белән мәктәп автобусларын җиһазландыру буенча чаралар күрергә.

7. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына өс киемнәре һәм аяк киемнәре җитештерүчеләргә яктылык кайтару элементларын куллануны киңәш итәргә.

8. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына 2016 елның 1 мартына кадәр:

физик культура һәм спорт учреждениеләре балансында булган, балаларны йөртү өчен каралган автомобиль транспортының билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерергә;

физик культура, спорт һәм яшьләр сәясәте учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрне йөртүче автобусларның оешкан рәвештә юлга чыгу тәртибен расларга.

9. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

2016 елның 30 октябренә кадәр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясе аша уза торган федераль автомобиль юлларында юл-транспорт һәлакәтләре китергән зыяннарны бетерү буенча тактик-махсус өйрәнүләр үткәрергә.

2016 ел дәвамында:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә, Татарстан Республикасының янгыннан коткару бүлекчәләрен «Беренчел ярдәм күрсәтү» курсы буенча укытуны оештырырга;

юл-транспорт һәлакәтләре китергән зыяннарны бетерүдә катнашучы Татарстан Республикасының янгыннан коткару бүлекчәләрен техниканың заманча үрнәкләре, һәлакәттән коткару җайланмалары белән җиһазландыруны дәвам иттерергә.

10. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә, 2015 елның 30 декабренә кадәр һәлакәтләрне киметү һәм юл хәрәкәте иминлеген арттыру чараларын массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмати яктырту буенча айлык план эшләргә.

11. «Тереклек эшчәнлеге иминлеге фәнни үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенә:

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән килештереп, юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә эшләүче республика массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын укытуны дәвам иттерергә;

2016 елның 1 июленә кадәр:

балалар өчен роликлы тимераякларда, самокатларда һәм скейтбордларда хәрәкәт итү кагыйдәләре турында әсбаплар һәм белешмәлекләр чыгарырга;

юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә закон чыгару инициативалары хакында җәмәгать фикере мониторингын үткәрергә.

12. «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенә:

кран белән идарә итү җайланмасы булган 6 данә эвакуатор сатып алу мөмкинлеген карарга;

исерек хәлдә кабат транспорт чаралары белән идарә иткән йөртүчеләр тарафыннан траспорт чараларын күчерү һәм саклау чыгымнарын каплау мәсьәләләрен законнар нигезендә җайга салу өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына мөрәҗәгать итәргә.

13. Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналарның һәм башка төрдәге техниканың техник торышын күзәтчелектә тоту идарәсенә 2016 елның 1 мартына кадәр тракторларның һәм үзйөрешле техниканың һәлакәт очраклары сәбәбен анализларга, анализ нәтиҗәләре буенча профилактика чаралары комплексын эшләргә.

14. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына республика әһәмиятендә булган гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында автоматлаштырылган авыр габаритлы тикшерүне кертүне дәвам иттерергә;

«Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» федераль казна учреждениесенә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә, юл-транспорт һәлакәтләре туплану урыннарын тикшерүне һәм анализлауны дәвам иттерергә һәм аларны бетерү эшен алып барырга;

«ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – «ГЛОНАСС+112» БДМС) базасында Төбәк навигация-мәгълүмат системасына муниципаль берәмлекләрнең транспорт инфраструктурасы турында даими рәвештә актуаль мәгълүмат кертүне тәэмин итәргә;

юл участокларын ремонтлау, капиталь ремонтлау һәм төзекләндерү кысаларында, I-б техник категорияле юл участокларында бүлүче полосада ике яклы киртәләр кую һәм ике һәм аннан күбрәк полосалы, ике яклы хәрәкәт итү булган юллар участокларында әлеге юнәлештә хәрәкәт итү өчен машиналар йөри торган өлеш өстендә 5.19.1 «Җәяүлеләр чыгу урыны» дигән юл билгесе белән Г-сыман багана кую эшен дәвам иттерергә;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларына:

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән берлектә, 2016 елның 30 мартына кадәр Торак йортларны капиталь ремонтлау программасы кысаларында күпфатирлы йортларның кырый диварларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләр буенча социаль реклама урнаштыруны дәвам иттерергә;

илкүләм стандартлар таләпләре нигезендә, беренче чиратта, белем бирү оешмалары янында җәяүлеләр хәрәкәте өчен имин һәм уңайлы шартлар тудыру чараларын тормышка ашыруны дәвам иттерергә;

җирле бюджет акчасы яки бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән юл хәрәкәте иминлеген арттыру чараларын финанслашуны тикшерүдә тотуны тәэмин итү;

юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча муниципаль максатчан программалар чараларын тормышка ашыруга бюджетларда чыгымнарны күздә тотарга;

торак пунктларда юл хәрәкәте иминлеген оештыру проектларын эшләүне дәвам иттерергә;

юл-урам челтәрендә һәлакәт участоклары санын киметү чараларын күрергә, юл билгеләрен юл хәрәкәте иминлеген оештыру буенча расланган проектларга туры китерү буенча планлы рәвештә эш алып барырга;

мәктәп укучыларын йөртүгә конкурслар оештырганда, тәҗрибәсе җитәрлек, матди-техник базасы һәм хәрәкәт итү составы булган йөртүчеләрне катнашуга кертергә;

балаларны йөртү өчен «ГЛОНАСС+112» БДМС ян як навигацияле җайланма белән җиһазландырылган М 1 һәм М 2 класслы автобусларны гына җәлеп итәргә.

15. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен азайту һәм алар сала торган зыяннар авырлыгын киметү буенча өстәмә чаралар турында» 2014 ел, 30 декабрь, 1069 нчы карары үз көчен югалткан дип санарга.

16. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков